РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» 09 2019 ел №681

Опека һәм попечительлек өлкәсендә
дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ
регламентларын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында " 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, 2008 елның 20 мартындагы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 7-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 28 августында № 1316 боерыгы белән, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 18.06.2012 ел, № 3680/12, № 3681/12, № 3683/12, 21.06.2012, № 3790/12, 22.06.2012 № 3873/12, № 3844/12, № 3845/12, 27.06.2012 №3938/12, №3939/12, №3940/12 боерыклары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1. Расларга:

1.1. Тәрбияләнүчеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик төрдәге интернат-йортларга юнәлтү турында карарлар бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №1).

1.2. Суд тәртибендә эшкә яраксыз яисә чикләнгән рәвештә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү яисә опекун яки попечительне билгеләүбуенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №2).

1.3. Балигъ булмаган бала мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №3).

1.4. Балигъ булган яшьтәге зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыру өчен опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №4).

1.5. Наемга опекага алынган затныкы булган торак тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №5).

1.6. Үз опекаларындагы затларның мөлкәте белән алыш-биреш ясауга рөхсәт алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №6).

1.7. Яшәү урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә опекага алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү учетыннан төшерү өчен опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №7).

1.8. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №8).

1.9. Опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №9).

1.10. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №10).

1.11. Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №11).

1.12. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын уллыкка алучылар булу һәм уллыкка алучылар сыйфатында исәпкә кую мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №12).

1.13. Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен алу буенча алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №13).

1.14. Ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №14).

1.15. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган гражданнарны (түләүле яки түләүсез шартларда) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №15).

1.16. Балигъ булмаганнарга эмансипация (балигъ булмаганнарны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №16).

1.17. Балигъ булмаган балага күчемсез милекне алу (отчуждение) буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №17).

1.18. Кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №18).

1.19. Балигъ булмаган балага акча вкладын алуга законлы вәкилгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта №19).

1.20. Ютазы муниципаль районында опекага (попечительлеккә) алынган баланы карап тоту өчен акча түләүне билгеләү һәм оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (20 нче кушымта).

1.21. Ютазы муниципаль районында баланы гаиләгә тәрбиягә биргәндә бер тапкыр бирелә торган пособие түләүне билгеләү һәм оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (21 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 9 апрелендәге «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 205 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының http://jutaza.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Оештыру бүлегенә өч эш көне дәвамында әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Г.Р. Гофман

2-74-68